**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
10.04.2019

КАРАР
ПР-82

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законын үтәү буенча җаваплы затларны билгеләү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законын, «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында"гы 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында "гы 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үтәүгә җаваплы итеп «Мәгариф идарәсе» МКУ билгеләргә.

2. Актаныш районы мәгариф идарәсе җитәкчесенә муниципаль районның ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны опекага (попечительлеккә) бирелгән балаларны карап тоту өчен айлык акчалата түләүләр башкару, опекун яки попечительләргә тиешле бүләкләр тапшыру өчен җаваплы зат билгеләргә.

3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесенә һәм айның 25 числосына кадәр әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән җаваплы затка ай саен ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тоту өчен бирелә торган айлык акчалата түләүләргә һәм опекун яки попечительләрне бүләкләү өчен юллама бирергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Ф. Нурлыевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.Ш.Бариев